БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ

# Әллүки

№10 - 2023



## Әминә ГАЛИБАЕВА: “Образга керү бик кызыклы икән!”

0+

podpiska.pochta.ru

Хәкимҗан ХАЛИКОВ

# Көз

Алтын-сары
Яфракларны
Җилләр саный.
Иртә-кичен
Суык бабай
Бармак яный.

Ник гомергә
Килми икән
Шушы язлар!..
Дигән кебек
Моңсу гына
Китә казлар.

Әнә инде
Юлга чыккан
Торналар да…
Бер үк сүзне
Кабатлыйлар,
Гүя, бар да:

– Суык бабай
Арттан җитеп
Харап булмыйк,
Оча торыйк,
Бара торыйк,
Тор-рыйк, тор-рыйк!



Рәссам Рида ШӘЙХЕТДИНОВА.

podpiska.pochta.ru

# Туган телен белгән югалмас

*Балтач районының Иске Балтач 1нче мәктәбендә туган телебезне өйрәнүгә зур игътибар бирелә.* Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Рима Мансурованың кызыклы да, мавыктыргыч та дәресләрен балалар бик ярата. Тырыш һәм талантлы мөгаллимәнең укучылары район, төбәк бәйгеләрендә призлы урыннар яулый. Туган тел атналыклары, милли йола-бәйрәмнәр күңелле үтә биредә. "Әллүки"нең тугры дуслары да бит әле алар! Бигрәк тә башлангыч сыйныфлар укытучысы Нәзилә Аллаярова җитәкчелегендәге 2 Б сыйныфы укучылары журналга язылуда өлгерлек күрсәтә.

– Бу укучылар белән нәрсәгә тотынсак та, җиңел генә башкарып куябыз. Туган телне өйрәнүгә, сәләтләрен үстерүгә теләкләре көчле, шуңа алар белән эшләве дә күңелле, – ди укучылары белән горурланып, Рима Рим кызы.

Сәләтле укучыларга һәм аларның остазларына уңышлар телик!

**Юлия ГЫЙЛЬВАНОВА.**







Фотолар сыйныф архивыннан.


podpiska.pochta.ru



**2** **Зирәк булу бик кирәк!**




*Дускай, рәсемнәр урынына сүзләр куеп, хикәяне укы.*

# Көзге табигать

*Хикәя*

Алтын көз җитте.  соңрак чыга, иртәрәк бата. Көннәр кыскара, төннәр озая.  алтынсу, сары төскә керә. Юкка гына көзне алтын, димиләр. Алардан  кебек тибрәлә-тибрәлә  коела. Бары тик  һәм  кына яшел килеш кала. Октябрьдә  ешрак ява.  корый, аларның орлыклары коела. Җил ул орлыкларны төрле якларга тарата.

Көзге  тып-тын. Анда инде җәйге көннәрдәге кебек  сайрамый. Аларның күбесе җылы якларга очып киткәннәр.

Әнә  тырышып өненә , ,  ташый. Ул бигрәк тә майлы  ярата. Аю да кышка ныклап әзерләнә. Җәй буена ,  ашый, кыргый  җыйган  белән сыйлана.  күп ашап нык симерә. Май шулай ук азык запасы булып исәпләнә. , ,  кышка ризык хәстәрләми. Алар кыш көне дә азык таба ала.  өлгереп җитүгә, кырдагы  үзенең оясына бөртек ташый башлый.

Табигать әнә шулай кышка әзерләнә.

Рәссам Фәкил МОСТАФИН.

podpiska.pochta.ru

# Татарчасы ничек була?

**1. Ребусны чиш.**




**2. Сүзләрне дөрес итеп тоташтыр.**

| | |
|---|---|
| яңгыр | саргая |
| кошлар | коела |
| яфраклар | җылы якка оча |
| агачлар | ява |

**2. Сүзләрне тәрҗемәсе белән тоташтыр.**

| | |
|---|---|
| фатир | дом |
| урам | город |
| шәһәр | деревня |
| авыл | улица |
| йорт | квартира |

Рәссам Фәкил МОСТАФИН.

podpiska.pochta.ru

# Сезне өйдә көтәләр!

***Бишбүләк 2нче мәктәбе укучылары махсус хәрби операциядә катнашучы яугирләргә хатлар язды.***

Мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, директорның тәрбия эшләре буенча киңәшчесе Айгөл Маликова әйтүенчә, һәр сүздә, һәр юлда балаларның самимилеге, ихласлыгы чагыла.

Ял вакытларында солдатлар үзләренә юлланган хатларны кулларына ала. Балалар кулы белән язылган изге теләкләр аларга рухи ныклык бирә. Шушы сабыйларның якты киләчәге өчен алгы сафта булганнарга туган якта, өйдә аларны сагынып көтүләрен белү бүген бик мөһим. Исән-сау җиңеп кайтыгыз, әтиләр, абыйлар!





Айгөл Маликова фотолары.

podpiska.pochta.ru